КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.06.2021 г.Казань № 120-П

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында урнашкан «Степаново авылының мәдәни катламы» археологик мирас объекты территориясенең чикләрен һәм файдалану режимын раслау, ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 12.07.2018 № 565 карары нигезендә боерык бирәм:

1. Әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында урнашкан «Степаново авылының мәдәни катламы» археологик мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

2. Әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында урнашкан «Степаново авылының мәдәни катламы» ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрен расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

3. Әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында урнашкан «Степаново авылының мәдәни катламы» ачыкланган археологик мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

4. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары Н.В. Прохоровага йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин